СОВЕТ
Наласинского
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
Арского муниципального района
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район,
422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Арча муниципаль районы
Наласа
авыл җирлеге
СОВЕТы
М.Вахитов урамы, 64 йорт. Наласа
авылы.
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Наласа авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

«04» октябрь 2016 ел №22

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 20 ноябренә Наласа авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2017 елда Наласа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым җыюга карата сез килешәсезме, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан тыш, алар өчен түләүләр күләме 300 сум тәшкил итә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Наласа авыл җирлеге составына керүче юлларга вак таш җәю: Наласа авылы,<br>- Яшьләр ур, 90 йорттан - М.Вахитов ур, 28 йорт;<br>- Үзәк ур, 67-82А йорт кадәр;<br>- Җинү ур, 194 -207 йортка кадәр;<br>- М.Җәлил ур, 216 - 241 йортка кадәр;<br>- М.Вахитов ур, 21-26 йортка кадәр.<br>Урта Бирәзә авылы:<br>- Файзрахмановлар ур;<br>- Татарстан ур, 51-55 йортка кадәр;<br>- Х.Такташ ур. | 50000<br>80000<br>80000<br>60000<br>44700<br>36000<br>10000<br>27200<br>60000 |
| | | | 411900 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов ур., 64 йорт, ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова